**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Петровский поселогы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

**08 апрель 2024 ел** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлегенең Петровский поселогы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2024 елда 5500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Петровский торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кышкы тоту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (роторлы чапкыч сатып алу).

Халык җыенында рәислек итүче: О.В.Охотникова

Ялаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова